РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

ГЛАВА ТЮЛЯЧИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

Ленина ул., д. 46, с. Тюлячи, 422080

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

ТЕЛӘЧЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШЛЫГЫ

Ленин ур., 46 нчы йорт, Теләче авылы, 422080

тел. (факс): (843) 602-11-89, E-mail: telache@tatar.ru, http://tulachi.tatarstan.ru/

**РАСПОРЯЖЕНИЕ** **БОЕРЫК**

№ 14 «21» апреля 2021г.

Теләче муниципаль районы территориясендә 2021 елда язгы кыр эшләрен нәтиҗәле оештыру һәм вакытында үткәрү буенча район штабы төзү турында

Теләче муниципаль районы территориясендә язгы кыр эшләрен үз вакытында һәм сыйфатлы башкаруны мониторинглау максатларында,

1. Теләче муниципаль районы территориясендә 2021 елда язгы кыр эшләрен нәтиҗәле оештыру һәм вакытында үткәрү буенча район штабы (алга таба – район штабы) төзергә һәм аның составын 1 номерлы кушымта нигезендә расларга.
2. Теләче муниципаль районы территориясендә 2021 елда язгы кыр эшләрен нәтиҗәле оештыру һәм вакытында үткәрү буенча район штабы төзү турында нигезләмәне 2 номерлы кушымта нигезендә расларга.
3. Район штабының «кайнар линия» телефон номерларын расларга: (84360) 21-2-53, 21-8-77, 21-1-89.
4. Теләче муниципаль районында Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек идарәсенә (Низаметдинов Р.Х.) 2021 елның 23 апреленнән дә соңга калмыйча район штабына 2021 елның язгы кыр эшләре буенча чаралар планын бирергә тәкъдим итәргә.
5. Әлеге боерыкның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Н. Н. Хаҗипов

Татарстан Республикасы
Теләче муниципаль районы
Башлыгының 2021 елның «21»
апрелендәге 14 номерлы
боерыгына 1 номерлы кушымта

Теләче муниципаль районы территориясендә 2021 елда язгы кыр эшләрен нәтиҗәле оештыру һәм вакытында үткәрү буенча район штабы составы

Район штабы рәисе:

| | | |
|---|---|---|
| Хаҗипов Н.Н. | – | Теләче муниципаль районы Башлыгы; |

Район штабы рәисе урынбасарлары:

| | | |
|---|---|---|
| Хәмидуллин И. Х. | – | Теләче муниципаль районы Башкарма комитеты Җитәкчесе; |
| Низаметдинов Р. Х. | – | Теләче муниципаль районы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек идарәсе башлыгы (килешү буенча); |

Район штабы әгъзалары:

| | | |
|---|---|---|
| Фәтхуллин А. Г. | – | Теләче муниципаль районы Башлыгы урынбасары; |
| Мөбинов И. В. | – | Теләче муниципаль район Советы аппараты җитәкчесе; |
| Гыйниятуллин Д. С. | – | район Башкарма комитеты Җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасары; |
| Зарипов И. С. | – | Россия Эчке эшләр министрлыгының Теләче районы буенча бүлеге башлыгы (килешү буенча); |
| Хуҗин Л. Й. | – | «Татмедиа» АҖ филиалы «Теләче-информ» мәгълүмат үзәге директоры (килешү буенча); |
| Миңнегулов И. Ә. | – | Теләче муниципаль районы Башкарма комитеты Җитәкчесенең территориаль үсеш һәм инвестиция эшчәнлеге буенча урынбасары; |
| Галиәхмәтов И. В. | – | ФДБУ «Россельхозцентр» Теләче районы бүлеге башлыгы (килешү буенча); |
| Баев И. Р. | – | Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек идарәсенең җитештерү маркетинг бүлеге башлыгы (килешү буенча); |
| Шәрипов М. М. | – | 134 -ЯКБ башлыгы. ФКУ «ТР буенча 7 ФЯХБ» (килешү буенча); |
| Нәзиров Х. Х. | – | Дәүләт техник күзәтчелек идарәсенең Теләче муниципаль районы бүлеге башлыгы (килешү буенча). |

Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы Башлыгының 2021 елның «21» апрелендәге 14 номерлы боерыгына 2 номерлы кушымта

НИГЕЗЛӘМӘ
Теләче муниципаль районы территориясендә 2021 елда язгы кыр эшләрен нәтиҗәле оештыру һәм вакытында үткәрү буенча район штабы турында

1. Теләче муниципаль районы территориясендә язгы кыр эшләрен нәтиҗәле оештыру һәм вакытында үткәрү буенча район штабы (алга таба - Штаб) Тконсультатив-киңәшмә органы булып тора һәм Теләче муниципаль районы Башлыгына хисап бирә. Штаб составы һәм аның нигезләмәсе Теләче муниципаль районы Башлыгы боерыгы белән раслана, үзгәрә.

2. Штаб үз эшчәнлегендә гамәлдәге законнарга, әлеге нигезләмәгә таяна.

3. Штаб үз эшчәнлеген иҗтимагый башлангычларда алып бара.

4. Штабның төп бурычлары булып тора:

- язгы кыр эшләренә әзерлек барышын мониторинглау;
- Теләче муниципаль районы территориясендә язгы кыр эшләренең барышын мониторинглау;
- язгы кыр эшләрен нәтиҗәле үткәрү өчен карарлар һәм тәкъдимнәр эшләү;
- язгы кыр эшләрен вакытында башкару белән бәйле мәсьәләләрне оператив хәл итү.

5. Штаб вәкаләтләре:

- оператив киңәшмәләр, шул исәптән күчмә киңәшмәләр үткәрү;
- кирәкле мәгълүматны соратып алу;
- тәкъдимнәр һәм нәтиҗәләр, аналитик белешмәләр әзерләү;
- язгы кыр эшләре барышын мониторинглауны һәм анализлауны үткәрү;
- утырышларда вазыйфаи затларны чакыру һәм тыңлау;
- тиешле дәүләт органнарына, оешмаларга, төрле милек формасындагы предприятиеләргә штаб эшчәнлегенә кагылышлы мәсьәләләр буенча мөрәҗәгать итәргә.

6. Штаб утырышлары, 2021 елгы язгы кыр эшләре тәмамланганчы,кимендә атнага бер тапкыр уздырыла.

7. Утырышлар шулай ук килеп туган мәсьәләләрне оператив хәл итү өчен дә чакырылырга мөмкин. Комиссия карарлары беркетмә белән рәсмиләштерелә һәм Теләче муниципаль районы Башлыгы тарафыннан раслана. Расланган беркетмә тиешле башкаручыларга җибәрелергә тиеш.

8. Штаб тарафыннан кабул ителгән карарлар, бәяләмәләр һәм башка карарлар тәкъдим итү характерына ия.

9. Штабның «кайнар линия» телефон номерлары: (84360) 21-2-53, 21-8-77, 21-1-89.